| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КОШМАН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2026 Кошман ав. № 13

«Җир салымы турында» 2015 елның 12октябрендәге 8 номерлы Кошман авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 декабрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы Кошман авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.3 статьяның 2 абзацында «, салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан билгеләнә» сүзләрен «салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан билгеләнә, исәпләнә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советының 2025 елның 25 декабрендәге 9 номерлы ««Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы Кошман авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар, 2027 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1.1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында, мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина